ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 728 2017 елның 23 ноябре

# Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 10 февралендәг 106 номерлы карары белән расланган реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210 - ФЗ номерлы Федераль закон, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2010 елның 18 декабрендәге 1491 номерлы карары нигезендә, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 10 февралендәге 106 номерлы карары белән расланган реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасындагы 2.5. пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) вәкил вәкаләтләрен раслый торган документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә) (6 нчы кушымта);».

1.2. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.5 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) реклама конструкциясенең тышкы күренешен билгели торган урынга бәйле рәвештә реклама конструкциясе (паспорты) урнаштыруга эскиз проекты, әлеге регламентка 3 нче кушымта нигезендә форма буенча ике нөсхәдә (аерым-аерым һәр реклама конструкциясенә).».

1.3. Административ регламентка 3 нче кушымтаны яңа кушымтада бирелгән редакциядә бәян итәргә.

1.4. Административ регламентка тәкъдим ителгән редакциядә 6 нчы кушымта өстәргә.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.И. Беляевка йөкләргә.

А.Г. Сәйфетдинов

6 нчы кушымта

Үрнәк

(Ышанычнамәнең төп нөсхәсе кирәк)

ЫШАНЫЧНАМӘ №

______________________________________________________________________
(оештыру-хокукый рәвешен күрсәтеп, оешманың исеме)

җитәкче _________________________________________________исеменнән
(ФИА ис. тулысынча)

_______________________________________________, паспорт сериясе_____ № ___
(Ышанычлы затның ФИА ис.)

бирү датасы___ ______________ 20__ ел, реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле документларны тапшыру, шулай ук Түбән Кама муниципаль районында реклама конструкциясен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү белән бәйле мәсьәләләрне карау комиссиясе тарафыннан килештерелгән документларны алу хокукын ышанып тапшыра.

Ышанычнамә гамәлдә _____алып______кадәр.


МУ Имза ФИА ис.
(Директор)

МУ Имза ФИА ис.
(Ышанычлы зат)

Ышанычнамә бирү датасы

3 нче кушымта

Реклама конструкциясен урнаштыруга эскиз проекты (паспорт)



Реклама конструкциясен урнаштыру өчен эскиз проекы (паспорт)

*Бәйләү схемасы картасы (тышкы реклама яисә мәгълүмат чаралары урнаштыру урынын шартлы рәвештә билгеләү)*

*Реклама чарасы макеты һәм аның техник үтәлеше*

Килештерү кәгазе:

Реестр номеры____«___»_____20__ел

Килештерү срогы:____________________

_________________________________________________

Конструкция хуҗасы:______________

___________________________________

Милек хуҗасы:____________________

___________________________________

Конструкция урнаштыру адресы:_____

___________________________________

Реклама чарасы объекты төре:_____

Элемтә өчен телефон номеры:________

«ТКМР» БК җитәкчесе урынбасары

«ТКМР» БК тышкы реклама белән эшләү секторы мөдире

_______________________________________________

«ТКМР» БК Төзелеш һәм архитектура идарәсе башлыгы

_______________________________________________

_______________________________________________

«ТКМР» БК җәмәгать оешмалары белән элемтә һәм милли мәсьәләләр бүлеге җитәкчесе

_______________________________________________